**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ АЙМАН АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
423739, Иске Айман авылы,
Яна ур.,
5а нчы йорт.
Тел.:(85552)3 44 52; факс:3 44 52;
E-mail saym.akt@yandex.ru

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ СТАРОАЙМАНОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИ-ПАЛЬНОГО РАЙОНА**
423739, село Старое Айманово
ул.Новая,дом 5а.
Тел.:(85552)3 44 52; факс:3 44 52;
E-mail saym.akt@yandex.ru

**29.01.2026ел** **РЕШЕНИЕ** **КАРАР** **№5**

## Актаныш муниципаль районы Иске Айман авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 24 маендагы 13 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 28.11.2025 ел, № 425-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының “Иске Айман авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Иске Айман авыл җирлеге советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы Иске Айман авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 24 маендагы 13 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 пунктның 5 пунктчасындагы 2 абзацта «проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төгәлләнмәгән төзелеш объектларыннан тыш» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүматы порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә урнаштырырга.

Актаныш муниципаль районы
Иске Айман авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе М.Р.Ахметханов